ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 47 от «02» 02 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 июлендәге 202 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2024 елның 24 гыйнварындагы 02-08-02-24 номерлы протесты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы «Торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 июлендәге 202 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.4 пунктында «янгын» сүзен төшереп калдырырыга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 июлендәге 202 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә бинаны, торак урынны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия (алга таба- Нигезләмә) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2. Комиссия составынан комиссия секретаре Р. М. Миңнехановны чыгарырга;

2.3. Комиссия составына Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенең баш белгече (баш архитектор) А.И. Сибгатуллинны – комиссия секретаре итеп кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

00000022 18

порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ / веб адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов